**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**НАРМОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**НАРМОНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

тел. (84373) 55-0-43, факс 55-0-43

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**18 .11. 2021** **№ 5**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең Чинчурино торак пунктында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Нармонка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 ст. нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Нармонка авыл җирлеге, Чинчурино авылы, Дряничкин урамы, 7В йорт адресы буенча урнашкан кибет бинасы янында 2021 елның 1 декабрендә 14 сәгать 30 минутка билгеләргә.

2. 2021 елның 1 декабрендә 16 сәгать 00 минутта Чинчурино авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Чинчурино авыл җирлегенең 2022 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Чинчурино Нармонка авыл җирлеге торак пунктында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибе вакытлыча билгеләнгән.

4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Чинчурино авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, I төркем инвалидлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәт итүгә чакырылган гражданнардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы гражданнардан тыш, сез риза буласызмы?, - алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү:

-Чинчурин т. п., яр буе ур., Революция ур., Дряничкин ур., Мәктәп ур., Совет ур., су белән тәэмин итү челтәрләренең проект-смета документациясен әзерләү;».

«КАРШЫ» “РИЗА”

5. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге башкарма комитеты Гражданнар җыенын оештырырга һәм үткәрергә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Татарстан

Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга. https://tetushi.tatarstan.ru/

7. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге башкарма комитеты Гражданнар җыенын үткәргәндә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге территориясендә яңа коронавирус йогышы (COVID-19) белән авыру очракларының барлыкка килүен һәм таралуын кисәтү өчен профилактик, санитар-эпидемияләргә каршы чараларны (COVID-19) үтәүне тәэмин итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Җитәкче** **Т.А. Хәкимов**